**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы**
**муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**
**“Күл-Черкен төп гомуми белем мәктәбе”**

| “Каралды” | “Килешенде” | “Расланды” |
|---|---|---|
| Методик берләшмә житәкчесе: | Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары: | Директор: |
| ______Абдуллина Р. М. | ______ *Гибадуллина Л.Р.* | ______Камалтдинова Ә. Ә. |
| Беркетмә №____ | | ____ номерлы боерык |
| “24” ______ *2019* ел. | “27” ______ *2019* ел | “31” ______ *2019* ел |

# I-IV сыйныфлар өчен “Әдәби уку (Туган тел)” предметыннан эш программасы

реализацияләү срогы 4 ел

**Төзеделәр: Абдуллина Рина Мөнүр кызы**
**Камартдинова Зилә Рөстәм кызы**

Педагогик киңәшмә
утырышында кабул ителде.
Беркетмә № 1
“ 26 ” август 2019нче ел

Күл-Черкен авылы
*2019* нче ел

## 1. Укыту предметын үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләре

### 1 сыйныф

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- кешеләрнең теге яки бу адымнарын, тормыштагы төрле очракларны гомум кабул ителгән нормалардан һәм кыйммәтләрдән чыгып бәяләү;
- яхшы һәм начарны аера белү;
- текст эчендә “яшәү”, үзеңнең хис – тойгыларыңны белдерү;
- башкаларның хис – тойгыларын аңлау, борчылу, кайгы – шатлыгын уртаклашу;
- үз – үзеңне үстерүгә омтылыш булдыру;
- авырлыкларны җиңеп, куйган максатка омтылу;
- үз фикереңне белдерә һәм яклый белергә омтылу.

**Метапредметлы нәтиҗәләр:**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

- дәреслектә җиңел ориентлашу, шартлы билгеләрне төгәл белү;
- дәреслек белән эшли белү;
- укытучы ярдәмендә уку эшчәнлегенең максатын билгеләү һәм формалаштыру;
- иллюстрация белән эш вакытында үзеңнең фикереңне, күзаллауыңны әйтергә өйрәнү;
- укытучы тәкъдим иткән план буенча эшләргә өйрәнү;
- шигырьне сәнгатьле уку һәм хикәяне эзлекле сөйли алуга ирешү;

**Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре**

- үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
- дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- уңышлылыгына бәя бирү;
- үз фикерләреңне телдән һәм язмача белдерү;
- уку бурычларын аңлау, аны чишү юлларын эзләү;
- уңышсыз уку эшчәнлегенең сәбәпләрен аңлау һәм конструктив эш итү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

- партадашын белән эшли, эшләрне үзенә һәм иптәшенә куша, үзенә тапшырылган эшне башкара белү;
- иптәше эшләгән эшнең нәтиҗәсе белән кызыксына белү;
- үз эшеңә бәя куя алу;
- чылбыр рәвешендә укый алу.

**Предметлы нәтиҗәләр:**

- кычкырып укыганда, индивидуаль темп белән йөгерек;иҗекләрне өзми сүзләп укый белү;
- ишеткән яисә сыйныфта укыган кыска әсәрнең эчтәлеген аңларга, төп мәгънәсен әйтеп бирә алу;
- төрле авторларның 3-4 әсәрен яттан укый белү;
- проза әсәрләрен шигъри әсәрләрдән аера белү;
- әдәби текстта җөмлә төрләрен, кабатлауларны, тыныш билгеләрен, ритм һәм рифмаларны таба белү;
- әсәргә ясалган иллюстрациягә туры килгән өлешне тексттан таба белү.

### 2 сыйныф

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- туган республикага, туган илгә, халкына, ил тарихына карата гражданлык нигезләре, үз милләтен ярату, татар булуы белән горурлану хисләре формалаштыру;
- табигать, халык, культура, дин төрлелеген берләштергән дөньяга социаль караш формалаштыру;

- башка халыкларның культурасына, тарихына хөрмәтле караш, башкалар фикеренә карата түземлелек формалаштыру;
- укучының торткан урынын, укучы ролен кабул итү, укуга карата кызыксыну уяту, укуның шәхсән мәгънәсен аңлауны формалаштыру;
- әхлакый нормаларны кузаллауга нигезләнеп, укучының үз эшләгән эшләре өчен шәхси җаваплылыгын, мөстәкыйльлеген үстерү;
- эстетик ихтыяҗ һәм хис формалаштыру;
- башкалар хисен аңлау, кайгырта белү, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, әхлакый хисләрен үстерү;
- балаларның дуслары, олылар белән хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру, конфликтлы ситуацияләрне булдырмау һәм алардан чыгу юлларын таба белүләрен үстерү;
- куркынычсыз һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, төрле тормыш ситуацияләренә һәм әдәби әсәрләрдәге геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- иҗади хезмәткә, эшнең нәтиҗәсенә мотивация булдыру, материаль һәм рухи байлыкларга сак караш формалаштыру.
туган республикага, туган илгә, халкына, ил тарихына карата гражданлык нигезләре, үз милләтен ярату, татар булуы белән горурлану хисләре формалаштыру;

**<u>Метапредметлы нәтиҗәләр:</u>**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

- сүзлекләр белән эш итеп, кирәкле сүзләрне эзләп табып, мәгънәсен ачыклау;
- берничә төрле информация чыганагы ( дәреслек, сүзлек, иллюстрацияләр)белән эшли белү;
- үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм информацияне бәяли белү;
- логик фикерләү чылбырын төзү;
- тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү;
-мәгълүмат җиткерүче символларны уку;
- тормыш тәҗрибәсен кулланып, ситуациянең моделе буенча текст төзү;
- тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару;
- материаль объектлар (фишкалар) кулланып биремнәр үтәү;
- анализ, гомумиләштерү нигезендә нәтиҗә чыгару

**Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре**

- көч һәм энергия туплау, конфликтларны һәм каршылыкларны чишү максатында ихтыяр көчен үстерү;
- белгәнне һәм белмәгәнне аера белү;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, рәсемнәр ярдәмендә биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү;
- үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
- бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру;
- дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;
- укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

- чылбыр рәвешендә эш итү;
- партадашы белән эшли белергә, һәркемгә эш бүлешергә, үз эшчәнлеген һәм иптәшенекен тикшерә белү;
- ике төрле караш булганда, бер фикергә килә белү;
- тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;
- күзаллау, фаразлау; логик фикер йөртү осталыгы;
- күршең белән хезмәттәшлек итү; фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру;
- үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;

- җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү.

**Предметлы нәтиҗәләр**:

- сүзләрне укыганда төгәл, дөрес итеп укый, уку тизлеген арттыра бара алу;
- әсәрне сүзләрне дөрес итеп әйтеп, кычкырып һәм эчтән укый белү;
- әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү;
- төрле авторларның 6-8 шигырен өйрәнү.
- кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү
- тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне аера белү.
- әсәрдәге төп геройга үз мөнәсәбәтеңне белдерү.
- укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контраст кебек алымнарны таба белү.
- төрле авторларның 6-8 әсәрен яттан укый белү;
- 2-3 татар, 1-2 рус классигының исемен әйтә белү;
- 2-3 хәзерге заман язучысының яки шагыйренең исемен, алар язган әсәрләрне һәм әсәрләрнең эчтәлеген;
- баланың үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен;
- китапның төрле элементларына карап, эчтәлеген билгеләү;
- мөстәкыйль рәвештә уку өчен китап сайлау;
- сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу. Әсәрдәге төп геройны характерлау, төрле әсәр геройларына чагыштырма характеристика;
- аерым бер элементы буенча китапта ориентлашырга өйрәтү

## 3 сыйныф

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасын күрсәтү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;
- дәрестә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану;
- үз фикереңне әйтә белү;
- иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;
- үз уңышларың-уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү;
- кече яшьтәге мәктәп баласы үзе тел берәмлекләрен танып, таныш һәм таныш булмаганнарга бүлә белү;
- биремнәр системасында ориентлашырга өйрәнү.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

- берничә төрле информация чыганагы ( дәреслек, сүзлек, иллюстрацияләр, картиналар, Интернет материал )белән эшли белү;
- сүзлекләр белән иркен эш итү;
- дәреслектә ориентлашырга,төс белән аерылган текст фрагментларын табарга, махсус билгеләнгән информация белән эш итү;
- үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм информацияне бәяли белү;
- логик фикерләү чылбырын төзү;
- тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү;
- мәгълүмат җиткерүче символларны уку;
- тормыш тәҗрибәсен кулланып, ситуациянең моделе буенча текст төзү;
- тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару;
- материаль объектлар (фишкалар) кулланып биремнәр үтәү;
- анализ, гомумиләштерү нигезендә нәтиҗә чыгару

**Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре**

- **к**өч һәм энергия туплау, конфликтларны һәм каршылыкларны чишү максатында ихтыяр көчен үстерү;

- белгәнне һәм белмәгәнне аера белү;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, рәсемнәр ярдәмендә биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү;
- үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
- бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру;
- дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;
- укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

- партадашы белән кечкенә һәм зур төркемнәрдә эшли белү;
- партадашы белән эш бүлешергә, үз эшчәнлеген һәм иптәшенекен тикшерә һәм бәяли белү;
- әсәр геройларының фикерләрен таба белү, башка фикерләр белән уртак нәтиҗәгә килү;
- тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;
- фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру;
- үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;
- җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү.

**<u>Предметлы нәтиҗәләр:</u>**

- текст өстендә эшләргә, тема һәм төп мәгънәне ачыклау;
- әсәрне сүзләрне дөрес итеп әйтеп, кычкырып һәм эчтән укый белү;
- әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү;
- төрле авторларның 6-8 шигырен яттан сөйләү;
- кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;
- кылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне, мәсәлләрне аера белу;
- әсәрдәге төп геройны характерлау, төрле әсәр геройларына чагыштырма характеристика;
- укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белу;
- сүзлекләрдән файдалану;
- аерым бер элементы буенча китапта ориентлашырга ойрәтү

## 4 сыйныф

**<u>Шәхси нәтиҗәләр:</u>**

- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасын күрсәтү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;
- дәрестә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану;
- үз фикереңне әйтә белү;
- иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;
- үз уңышларың-уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү;
- кече яшьтәге мәктәп баласы үзе тел берәмлекләрен танып, таныш һәм таныш булмаганнарга бүлә белү;
- биремнәр системасында ориентлашырга өйрәнү

**<u>Метапредметлы нәтиҗәләр:</u>**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

- берничә төрле информация чыганагы ( дәреслек, сүзлек, иллюстрацияләр, картиналар, китапханәдән алынган китаплар, Интернет материал )белән эшли белү;
- вакытлы матбугат белән эшли белү;
- үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм информацияне бәяли белү;
- логик фикерләү чылбырын төзү;
- тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү;

- мәгълүмат җиткерүче символларны уку;
- тормыш тәҗрибәсен кулланып, ситуациянең моделе буенча текст төзү;
- тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару;
- материаль объектлар (фишкалар) кулланып биремнәр үтәү;
- анализ, гомумиләштерү нигезендә нәтиҗә чыгару

**Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре**

- көч һәм энергия туплау, конфликтларны һәм каршылыкларны чишү максатында ихтыяр көчен үстерү;
- белгәнне һәм белмәгәнне аера белү;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, рәсемнәр ярдәмендә биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү;
- үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
- бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру;
- дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;
- укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

- партадашы белән кечкенә һәм зур төркемнәрдә эшли белү;
- инсценировкалар вакытында төрле рольләрне башкара белү;
- ике төрле караш булганда, бер фикергә килә белү, үз фикерен әсәрдән өзекләр белән ныгытырга, иптәшләрене җавапларын игътибар белән тыңлау;
- әйтелгән фикерне раслау өчен, тексттан өземтәләр китерергә, соңгы нәтиҗәнең дөреслегенә инану, җавапларны бәяләү; тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;
- фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру;
- үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;
- җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү.

**Предметлы нәтиҗәләр:**

- әсәрне сүзләрне дөрес итеп әйтеп, кычкырып һәм эчтән укый белү;
- әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү;
- төрле авторларның 6-8 шигырен яттан сөйләү;
- кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;
- тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне, мәсәлләрне аера белу;
- әсәрдәге төп геройны характерлау, төрле әсәр геройларына чагыштырма характеристика бирү;
- укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белу;
- сүзлекләрдән файдалану;
- аерым бер элементы буенча китапта ориентлашырга ойрәтү
- 2-3 балалар газетасы яки журналы турында сөйли белү.

# 2. Укыту предметының эчтәлеге
## 1 сыйныф

| Бүлекнең исеме | Кыскача эчтәлеге |
|---|---|
| Әлифба чоры | Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле.Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү. Схемада сузык авазны башта түгәрәк, ә тартыкларны квадрат, соңыннан транскрипция билгесе белән күрсәтү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өлге элементы ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни “киеме” буларак образлы күзаллау булдыру. Баш һәм юл басма хәреф формаларын төзү.<br>Табышмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү.<br>Укучылар татар теле авазларының сузык һәм тартык авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә, тартыкларның яңгырау һәм саңгырау булуын, сүзнең иҗекләргә бүленүен, сүзләрнең предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтен белдерүләрен, ярдәмче сүзләрне белергә тиешләр. Һәр укучы, үзенә генә хас темпта, басма текстларны орфоэпик нормаларга туры китереп укый.<br>Милли төбәк компоненты: Татар халык авыз иҗаты белән танышу. |
| Халык авыз иҗаты һәм әдәбият | Халык авыз иҗаты турында гомуми кузаллау. Авторларның булмавы, телдән сөйләм, практик-уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр. Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләр. Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек формаларын практик үзләштерү. Аптыраткыч әкиятләр сере. “Саескан” әкияте.<br>Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикерләре(әсәр исеме, геройларга характеристика, авторлар бәяләмәсе)<br>Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:<br>Укучылар халык авыз иҗаты әсәрләрен аера, бишек җыры, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләрнең берничәсен яттан, әкиятләрнең кыскача эчтәлеген белергә тиеш.<br>Милли төбәк компоненты: Татар халык авыз иҗаты белән танышу. |
| Әсәрнең эмоциональ тоны | Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләр. Әсәрләрне телдән кычкырып, ятлап укыганда эмоциональ характерын чагылдыру.Тавыш төсмерләре-интонация, тон, тавыш көче, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләр, ымнар.<br>М. Галиев «Кайтаваз». Ш.Галиев «Чагу», «Таяк». Л.Лерон “Буталмышлар илендә”. Х.Халиков “Бии белмәгән аю ”. Татар халык әкияте “Аю белән өч кыз”. “Песәй “ әкияте. Яңгыравык шигырьләр. Р.Бәшәр “Бал корты”, “Авазлар”. Э.Шәрифуллина “Бәйрәм ашы-кара каршы”. Шаян шигырьләр.Р.Корбан “Көчек”,”Яңгыр яуганда”. ”Чәчәкләрне ни өчен өзәргә ярамый”.<br>Милли төбәк компоненты: Якташ татар язучылары иҗаты белән танышу. |
| Әдәби сәнгатьлелек чаралары | Текстларны анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел кузаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: рифма, ритм төшенчәсе бирү.<br>Х.Халиков “Әллә ул да белә микән?”. Р. Вәлиева “Урман әкияте”. Әдәбиятта фантазия. Р.Кутуй “Төнге әкият”. З.Хөснияр “Шүрәле”. Р.Миңнуллин “Шүрәлесез урман”, Х.Халиков “Әгәр күрә белсәгез”, “Тартар белән сөйләшү”, “Аксак кәҗә”. Р.Вәлиева “Кыңгырау чәчәк”. |

| | |
|---|---|
| | Укучылар әсәрләрне анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга, ритм, рифма төшенчәләрен аңларга тиешләр.<br>Милли төбәк компоненты: Татар халык авыз иҗаты белән танышу. |
| Әдәби жанрлар | Жанрлар турында гомуми кузаллау булдыру: хикәя, шигырь. Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрь матурлыкны тоя белергә өйрәтә. Рифма белән танышу: аны таба, куллана белергә күнектерү.<br>Х.Халиков “Көймәче мәче”. М.Әгләмов “Килсен безгә әкият”. Р.Харис “Сине көтә тыныч таң”. Х.Туфан “Юкмыш бабай малае”.<br>Укучылар әдәби жанрларны (шигырь, хикәя) аера, әсәрдәге геройлар турында үз фикерен әйтергә, матурлыкны күрә һәм аңлата белергә тиешләр.Контроль төрләре: телдән тест. Милли төбәк компоненты: Якташ татар язучылары иҗаты белән танышу. |

## 2 сыйныф

| **Бүлекнең исеме** | **Кыскача эчтәлеге** |
|---|---|
| Белдекле Керпедә кунакта | Г.Тукай ”Су анасы, “Кәҗә белән сарык әкияте ”,”Кәҗә белән бүре”, “Эш беткәч, уйнарга ярый”, “Сабыйга” “Батыр әтәч” татар халык әкияте. Йолдыз “Кояшка җавап” . “Әтәч патша” Г.Бәшәр. “Әкият сөйлә”. Г.Бәшәр. “Әкият сөйлә”. “Бүдәнә белән Төлке”.Тизәйткеч.. . “Аю белән Төлке” әкияте, М.Гафури “Тавык белән Үрдәк”, ”Тавык нигә суда йөзә алмый” гуцул халык әкияте. “Хәйләкәр керпе” Г.Юнысова “Керпе кайгысы “Тылсымлы әкиятләр. “Гөлчәчәк” .”Өч кыз” әкияте әкияте, Ш.Галиев. “Җизни әкияте”. А.Алиш “Бикбатыр белән Биккуркак” Ш.Галиев. “Ник соң итек җитмәде “Котбетдин мәргән”(мәзәк маҗара). Уйдырма әкиятләр. Н.Исәнбәт “Мыраужан агай хәйләсе”. З.Мансур. “Кырмыска һәм малай”, Р. Миңнуллин “Черкиләр җыры”.“Кап та коп” уены. Автор әкиятләре. Г.Вәлиева “Су әкияте” .Хайваннар турында әкиятләр. Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре.<br>Тылсымлы әкиятләр. Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру. Тылсымлы предметлар (эченнән гаскәр чыга торган таяк, төрле ашамлыклар тулы тырыс, хәзинәсе бер дә кимеми торган сумка, кеше күзенә күрсәтми торган бүрек, җилән, зур атлата торган итек, дошманны кырып сала торган кылыч һ.б.), герой куллана торган тылсымлы әйберләр: тарак, көзге, кайрак, балдак. Тылсымлы булышчылар (җәнлекләр: әтәч, бүре, аю, куян, шулай ук убырлы карчык Һ.6.), тылсымлы төсләр (ак һәм кара). Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы (табигать көчләре, кешеләрнең хайваннарга, үсемлекләргә әверелүе).<br>Тылсымлы әкиятләрнең төзелеше (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә баруы, кабатланулар, билгеле бер ритм, әкиятне истә калдыру). |
| Белмәмештә кунакта | Шигъри формада язылган әсәрләр (. Йолдыз. “Белмим”, Ф. Яруллин. “Ике кеше” ,Л Лерон “Сараватта кем ята?”,Л.Шәех “Ике “мин”, Ж.Дәрзаман.“Солдат булдым”, Р.Вәлиева “Замана баласы”, Г.Морат “Татар космонавты”, Ф.Яруллин. “Эшнең анын берние юк”. Л.Лерон “Үскәч”, хезмәт турында мәкальләр. ) .<br>Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби |

| | |
|---|---|
| | алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү). |
| Укымышлы Ябалак янында | Г.Тукай "Буран", В. Нуриев"Җәйге кар", Япон шигырьләре. Н.Ахунова "хоккулар"ы, Р.Вәлиев "Умырзаялар", Р.Фәйзуллин "Кышын","Язгы кәеф" Өчьюллыклар, Р.Миңнуллин "Яз керде өебезгә", Э.Шәрифуллина "Алтын балык".<br>Җанр үзенчәлекләре: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы; әхлакый проблемаларның актуальлеге; уйдырмалар. Хикәянең төп мәгънәсе. Хикәя исеменең эчтәлеккә туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характерларының сөйләмнәре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. |
| Аю өнендә | И.Лерон . "И ямьле дә соң дөнья!", И.Туктар. "Урман букеты", Р.Миңнуллин ."Чыршы әйләнәсендә" , Р.Харис "Төсле рәсем", «Матурлык турында», А. Юнысова «Телевизор, Ш.Галиев "Яңа фотоаппарат", Ф. Садриев "Тәҗрибә", Р.Миңнуллин "Рәсем", Р.Сарби "Рәсем", Р. Мингалим "Кызык рәсем", Р.Миңнуллин "Ак кыш", " Р.Харис "Төсле рәсем", «Матурлык турында», А. Юнысова «Телевизор, Ш.Галиев "Яңа фотоаппарат", Ф. Садриев "Тәҗрибә", Р.Миңнуллин "Рәсем", Р.Сарби. "Рәсем", Р. Мингалим "Кызык рәсем", Р.Миңнуллин "Ак кыш»<br>Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү). |
| Хыялда тудырган дөнья | Г.Юнысова "Күзләр", Г. Гыйльманов"Күңел күзе", М.Әгъләмов "Ямь-яшел", М. Шабаев. "Идел суы". Ш.Галиев "Һәркем әйтә дөресен"<br>Ф.Тарханова "Диана төше" Н.Арсланов "Сезнеке", Р. Миңнуллин. "Ай нәрсәгә охшаган?"<br>Р.Миңнуллин "Беркемгә дә охшамаган", Н.Мадьяров "Үз шәүләсен куркыткан", З.Минһаҗева "Су иясе", Н.Мадьяров «Өйгә керә алмады", Ф. Садриев"Боз өстендә" , Г.Шаһи "Тамчы", Ф.Зыятдинова "Тәрәзәләр", Р.Фәйзуллин "Бинокль", Г.Тукай"Карлыгач", Н.Арсланов "Карлыгачкай", Р.Хафизова "Күңел күзе" ,Җ.Дәрзаман "Балык тотты", Б.Рәхмәт "Гөлйөзем белән чебен", Р.Корбан. "Чыпчык". Җ.Дәрзаман "Балык тотты", Б.Рәхмәт "Гөлйөзем белән чебен", Р.Корбан"Чыпчык", Ф.Зиятдинова "Карга белән Шөпшә", Ш. Галиев "Сизгер суган", Л. Лерон "Керән" , Җ.Дәрзаман "Күбәләк кар", А.Нигъмәтуллин"Кар", Г.Ибраһимов "Кар ява", А.Әхмәт "Кышкы матурлык", Р.Миңнуллин "Кем соң минем Әби?", Л.Шәех. "Картлар нигә шатлар?" Ф Зиятдинова "Өебезнең кояшы", З.Насыйбуллина "Тик бер нәрсәне белми", Ә.Моталлапов "Кечкенә дә төш кенә", Р.Миңнуллин "Йорт агачлары", Р.Бәшәр "Иске өй", Г.Тукай "Бу кайчак була?", Р.Корбан "Ел фасыллары", Г.Афзал "Беренче кар",Ф.Яруллин "Яз",Л.Лерон "Яз", Р.Миңнуллин "Төрле кешеләр була", "Юкка малай булганмын", В.Хәйруллина "Миңа охшаган малай" , Р.Вәлиева "Шатлык кызы ", М. Җәлил "Бер шигырь".<br>Үзбәя бирә белү, табигатьне җанлы итеп күрә белү, табигатьнең кабатланмас кыйммәтен аңлый белү, дөньяга шигъри караш белән объектив караш арасындагы аерманы аера белү, гади генә предметлардан да тылсым күрә белү, бер тамчы суда да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген аңлау, бинокль аша да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген белү, матурлыкны "Күңел күзе" белән күрә белү, күзәтүчән, игътибарлы һәм хыялый була белү, төрле ситуациядән чыгу өчен оптимистик карарлар кабул итү, тема һәм фикер уртаклыгын таба белү, авторның төп фикерен аңлый белү. |
| Балалар газета-журналлары | Газета-журналларның ни өчен вакытлы матбугат дип аталуын, яңалык белән гайбәт арасындагы аерманы аера белү. Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру |

| | |
|---|---|
| | (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Татар телендә чыга торган балалар журналларын белү, журналларда һәм газеталарда ориентлаша белү. Р.Миңнуллин "Малайлар сөйләшә", Г.Морат "Мультфильмнар карыйбыз» Ш.Галиев "Тынлык". |
| Табигать-серле һәм җанлы дөнья | "Урманда бәйрәм булган,", Ш.Галиев "Үсә урман" Р.Миңгалим "Якты тәрәзә каршында", Ә.Еники "Кышкы урман", Йолдыз "Бәхетле агач". И.Туктар "Кышкы урман", Ф.Сафин"Якты күл сагышы", М.Фәйзуллина "Агачлар да күлмәк алыштыра", Р.Газизов "Ял көнендә"Йолдыз "Салават күпере", Сәхаб Урайский "Туган ил" Л.Лерон "Тишек хәтер"Р Мингалим "Кызык нәрсә", В Нуриев "Шүрәле". Әсәрләрне анализлый белү, рәссамнарның матурлыкны буяулар белән бирү үзенчәлекәрен белү, картиналардагы матурлыкны күрә белү, табигатьнең матурлыгын күрә белү. |
| Көлек ничек туа? | Л.Лерон "Тишек хәтер", Р Мингалим "Кызык нәрсә", В Нуриев "Шүрәле", М.Галиев "Көзге каршында", М.Шабаев "Зәңгәр песи", Р.Вәлиева "Ак песи", М.Галиев "Көзге каршында", М.Шабаев "Зәңгәр песи", Р.Вәлиева "Ак песи" Э.Шәрифуллина "Оттырды", Л.Лерон "Гаҗәп хәлләр" Йолдыз "Ялган хакында чын" М.Галиев "Тамаша", Г. Мөхәммәтшин "Көчле булсам", Ф.Яруллин "Композитор чыпчыклар", Л.Ле-рон "Камилнең көләсе килә", Р.Вәлиева "Яңа көрәк Йолдыз. "Матурлык",Рафис Корбан "Кояш- безнең дустыбыз". Капма-каршылыкның көлке тудыруын аңлау, үзеңнең кимчелекләреңне әсәрләр аша аңлау, бетерү өстендә эшләү, язучыларның кызыклы хәлләрне җиткерү алымнарына төшенү, юмор хисен аеру, мәзәк өлешне таба белергә өйрәнү, чыга алмаслык кыен хәлләрнең булмавын ачыклау. |

## 3 сыйныф

| **Бүлекнең исеме** | **Кыскача эчтәлеге** |
|---|---|
| Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз | Табигатьнең гүзәллеген әдәби һәм сәнгать әсәрләре аша аңлату. Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтеп барырга, күргәннәрең белән уртаклашырга өйрәтү.Кешеһәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау.Әйләнә-тирә дөнья матурлыгының шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуына инандыру. Шигырьләрдә чагыштыру, сынландыру,эпитет.Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү). Б. Рәхмәт "Иң күңелле чак",Р. Хисмәтуллин «Июль аланы», Р. Вәлиева "Җәй һәм бала",М. Галиев «Җиләктән кайтканда», М. Мирза "Көздә бермәл", "Көз", "Болыт", Б. Рәхимова «Шук болытлар, батыр җил, якты кояш», М. Гафури "Болын", Н. Дәүли «Бала болыт», . Р. Корбан "Көз нигә моңая", Р. Вәлиева "Яңгыр, яу!", "Китмә әле, бераз тор", Йолдыз "Салават күпере", М. Әлимбаев "Салават күпере", Л. Лерон «Яңгырның ял көне», М. Җәлил "Яңгыр", Р. Мингалим «Август каеннары», Ш. Маннур "Көзге урманда", З. Туфайлова «Яфрак ява», Х. Әюпов «Әбиләр чуагы», К. Тәхау "Көзге урман", Р. Әхмәтҗан "Соңгы яфрак", М. Мазунов «Карап торам», Г. Хәсәнов «Кыр казы», Г. Бәширов «Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе», Н. Гыйматдинова «Казлар», |

| | |
|---|---|
| | Г. Остер «Серне ачты», В. Хәйруллина “Тәрбияче попугай”, Н. Сладков “Күзалдавычлар”, Р. Әхмәт “Сыкы”, Н. Сладков “Кем остарак”, Р. Корбан “Мәктәпкә озату бәйрәме”, Г. Паушкин “Кыш”, Г. Рәхим “Безнең тауда”, Н. Әхмәдиев “Чишмәгә суга барам”, К. Кәримов “Кышкы мәтрүшкәләр”, Н. Гыйматдинова Сарбай”. |
| Чагыштырулар серенә төшенәбез | Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.<br>Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау.<br>Әфган халык әкияте: “ Иң яхшы дару”, “Табышны ничек бүләргә?”, “Кабартма”; Уйгур халык әкияте: “Тылсымлы китмән”; Инглиз халык әкияте: “Көрән төстәге пингвин баласы”; Монгол халык әкияте: “Әтәч таңда нигә кычкыра?”; Манси халык әкияте: “Куянның колагы нигә озын?”; Кабарда халык әкияте: “Җәнлекләр патшасы”; Венгр халык әкияте: “Комсызлык бәласы”; Африка негрлары әкияте: “Сырны ничек бүлгәннәр?”; Эстон халык әкияте: “Куянның ирене нигә ярык?”; Эвенк халык әкияте: “Әтәч нигә кычкыра?”; Казакъ халык әкияте: “Юмарт дөя”; Нугай халык әкияте: “Карт һәм су анасы”; Норвегия халык әкияте: “Кабартма”; Алман халык әкияте: “Сандугач белән Аю”; Каракалпак халык әкияте: “Җәй белән Кыш нигә күрешми?”; Латыш халык әкияте: “Шайтанга ничә яшь?”; Литва халык әкияте: “Итагатьле мәче”, Л. Лерон “Әкияти башламнар”, Йолдыз “Охшашлык”, Э. Шәрифуллина “Әкият кайда?” |
| Кешеләрнең хыялларын аңларга тырышабыз | Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы – тыңлаучыга табигый көчләрнең серен , әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү. Уйдырмаларның максаты – тыңлаучыларны дөньяда булмаган,уйлап чыгарылган хәлләр белән шаккатыру.<br>Л. Лерон “Хыял”, Йолдыз “Антенналы бәрәңге”, Л. Лерон “Хыялый Акбай”, Ә. Габиди “Тере антенналар”, Л. Лерон “Мәче малае Шукбай”, “Шукбай балык тота”, “Хат”, Ф. Мөслимова “Хыялый”, З. Гомәрова “Хыялларым”, Б. Рәхмәт “Ничек өйрәнергә”, Р. Фәйзуллин “Тугайда”, А. Әхмәтгалиева “Болытта җиләк үсә”, Ф. Садриев “ Юкка көттеләр”, А. Гыйләҗев “Суык”, А. Аланазаров “Дустымны эзлим2, В. Хәйруллин “Кем булам”, Йолдыз “Этем югалды бүген”, Р. Гыйзәтуллин “Батырлык”, Г. Рәхим “Иске самавыр торбасы”. |
| Ярату турында | “Ярату” төшенчәсенең мәгънәсен әдәби әсәрләрдәге вакыйга һәм образлар язмышы аша аңлату: гаиләне хөрмәтләү, гаилә әгъзаларына, туган җиргә карата ярату хисләре, кече туганнарыбызга мәхәббәт. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып тану.<br>Р. Вәлиев “Барысын да яратам”, Ш. Маннур “ Яратам”, Р. Вәлиева “Чыпчык”, М. Хөсәен “Китап”, С. Урайский “Туган ил”, А. Гыймадиев “Шәмси маҗаралары”, Н. Кәримова “Авылым җыры”, В. Нуриев “Кем катырак суга?”, Р. Вәлиева “Яңгыр белән Кояш”, Г. Сабитов “Тәүге шатлык”, Ә. Баянов “Тургай”, Н. Гыйматдинова “Болын патшасы”, А. Әхмәтгалиева “Безнең чишмә”, Г. Бәширов “Беренче кар”, Н. Сладков “Кышкы җәй”, М. Мазунов “Яңа карлар ява”, И. Солтан “Кар ник шыгырдый?”, И. Солтан “Кар ник ява?”, Р. Мәннан |

| | |
|---|---|
| | “Кыш килә”, Ф. Зыятдинов “Муллык билгесе”, М. Мирза “Кышның китәсе килми”, Р. Миңнуллин “Кар бәйрәме”, С. Урайский “Кыш шатлыгы”, Р. Вәлиева “Каникул вакытында”. |
| Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз | Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше. Бөтен дөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж.Лафонтен, И.Крылов, татар мәсәлчеләре К.Насыйри, Г.Тукай,М.Гафури, Г.Шамуков, Ә.Исхак һәм башка язучылар әсәрләрен өйрәнү. Төрле халык мәкальләре . Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып тану. Мәсәл һәм экиятне чагыштыру. Мәсәлләрнең хайваннар турындагы экиятләрдән килеп чыгуы. Мәсәлләрнең төп асылы, эчтәлеге. Мәсәл моралендә мәкальләр куллану. Мәсәлләрнең тәрбияви роле.<br>Эзоп “Давыл белән Кояш”, Г. Тукай “Җил илә Кояш”, Н. Исәнбәт “Ябалак белән Чыпчык”, татар халык әкияте “Ябалак белән чыпчык”, Ф. Яруллин “Мактану бәласе”, К. Насыйри “Төлке белән Әтәч”, М. Гафури “Мәймүн белән күзлекләр”, “Чикерткә белән кырмыска”, Г. Тукай “Көзге белән маймыл2, Г. Шамуков Көзге белән Маймыл”, Т. Яхин “Карга белән Төлке”, Ф. Яхин “Сыр бәласе”, Г. Шамуков “Карга белән Төлке”, Ф. Яруллин “Хәйләкәр куян”, М. Гафури “Ике белән бака”, В. Гаршин “Ил гизүче бака”, В. Радлов “Карганың бәласе”, Л. Толстой “Зирәк Чәүкә”, К. Насыйри “Комсыз эт”, С. Шакир “Таш белән Кырмыска”, Ә. Исхак “Карт Имән белән яшь егет”, М. Гафури “Ике чебен”, М. Саттар “Кырмыска белән тирес корты”, Г. Тукай “Яшь агач”, Г. Тукай “Төлке белән йөзем җимеше”, Ә. Исхак “Төлке белән виноград”, Г. Вәлиева “Заман әкияте”, Г. Тукай “Аккош, Чуртан һәм Кыскыч”, И. Крылов “Аккош, Чуртан һәм Кысла”, М. Гафури “Кәҗә белән Төлке”. |
| Көлке серләрен эзлибез | Шигырьләрдә автор фикерен аерып алу. Шагыйрьнең кимчелекләрдән көлүе. Көлкеле әсәрләрдә көлке китереп чыгарган сәбәпләрне табу.<br>Ш. Галиев “Иншаның файдасы”, “Сүзләре һәм үзләре”, В. Нуриев “Инша”, Л. Лерон “Иртән уянасың килмәсә”, Сүз тыңлыйсың килмәсә”, “Инша”, Р. Вәлиева “Көчле укучы”, “Сыер эзләгәндә”, К. Тәңрекулиев “Эшчән” Гельды”, И. Юзеев “Хатасыз ничек язарга?”, Р. Миңнуллин “Хаталар өстендә эшләү”, Г. Морат “Үскәч кем булырга”, “Тиргиләр”, Р. Низамова “Табигать күренеше”, Р. Фәйзуллин “Ничек яхшы булырга?”, Йолдыз “Ике җаваплы табышмак”, Н. Кәримова “Кое чыпчыгы”, З. Туфайлова “Трай”, А. Алиш “Утлы йомрка”, Р. Вәлиев “Минеке”. |
| Герой ничек туа? | Автор әкиятләрендә, нәкъ халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә тезелүе, аерым сүзләрнең ритмик кабатланып килүе. Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Язның тәүге үзенчәлекләрен әсәрләрдән табу.<br>Ф. Яруллин “Тылсымлы ачкыч”, Р. Мингалим “Уйларга кирәк”, Р. Харис “Берсе калсын иде”, Р. Вәлиева “Кышкы ямь”, Йолдыз “Белмәгәнен белми”, М. Мирза “Язның тәүге көннәре”, Г. Хәсәнов “Корташар”, “Гөблә”, “Май”, Ә. Рәшит “Яшенле яңгыр”, Г. Гыйлман “Көзге урман”, Ф. Садриев “Белемле әби”, Х. Халиков “Витаминлы аш”, Н. Гыйматдинова “Дару”. |
| Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз | Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны табу.Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы ( тавышны күтәрү, түбәнәйтү).<br>Хикәя геройлары , аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы.Авторның үз героена мөнәсәбәте.Геройларга чагыштырма характеристика.Герой яшәгән тирәлек,пейзаж.<br>Р. Фәйзуллин “Онытма син!”, М. Мирза “Идел-йорт”, “Без бабайсыз үстек”, Р. Рәкыйпов “Мин яратам сине, Татарстан!”, Л. Шагыйрьҗан “Сөембикә |

| | |
|---|---|
| | манарасы”, В. Нуриев “Хуҗалар тавы”, Х. Туфан “Казан”, З. Гомәрова “Батырлар хакында”, Р. Харис “Сугыш турында сөйләшә картлар”, “Игенче җыры”, Г. Гыйлман “Нәсел агачы”, “Дәү әтинең әтисе”, “Универсиада”,В. Хәйруллина “Хозурлык һәм горурлык”, Ф. Кәрим “Ант”, Ватаным өчен”, М. Җәлил “Кичер, илем!”, Х. Халиков “Рәхмәт сезгә, ветераннар!”, В. Нуруллин “Бүреләр, үгез һәм без”, С. Рәхмәтуллин “Сандыктагы хәзинә”, Р. Мәннан “Без музейга барабыз”, Г. Ахунов “Канатлар кая илтә?”, Г. Моратов “Корыч шулай чынықты”, И. Юзеев “Матурлыкны гына алып кит”, М. Рафиков “Җир көены2, Г. Бәширов “Безнең Татарстан”, Р. Фәйзуллин “Нефть”, “Безнең КамАЗ”, Йолдыз “Спортчы Шүрәле”, Р. Миңнуллин “Кунакка килегез”. |

# 4 сыйныф

| **Бүлекнең исеме** | **Кыскача эчтәлеге** |
|---|---|
| Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез | Халык авыз иҗаты.<br>Борынгы халыкның тормышы , кеше һәм табигать арсындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы, тотем хайваннар һәм тотем үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.<br>“Җир йөзендә беренче яшәгән кешеләр”, ”Җир ничек барлыкка килгән?”,” Борынгы легендалар ни сөйли?”, “Җир ничек яралган?” (легенда), “Күкнең күтәрелүе (хикәят), “Айдархан һәм сәхабәләр, (легенда), “Пәйгамбәрнең туувы һәм аның балачагы”, “Абага чәчәге (хикәят Г.Кутуй “Рөстәм маҗаралары”.), “Ак бүре”(риваять), “Кырык кыз”( риваять), “Мәрҗан каласы һәм унике кыз” (хикәят), “Дөнья яратылу турында” (миф), “Хапи алла турында” (миф), “Чыршы ни өчен мәңге яшел?” (легенда) . әкиятләр: “Ак байтал”,“Ак бүре”, “Еланнар патшасы Шаһмара”, “Үги кыз” , “Ике кыз”, “Бумеранг”(Австралия халкы әкияте). |
| Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз, ә автор әкиятләре хисләр дөньясына чакыра | Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар, аларның килеп чыгышы. Риваять һәм легендаларда бирелгән вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.<br>. Автор әкиятләренең халык әкиятләре белән охшашлыгы (жанр һәм сюжет).<br>Халык әкиятләрендәге тылсым юлы белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.<br>Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.<br>Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Символик төшенчәләр. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.<br>Борынгы язучылар һәм татар әдәбияты классиклары әсәрләре.<br>Кол Гали “Кыйссаи Йосыф”. “Кол Гали” Р.Зәйдулла хикәяләвендә.“Кыйссаи Йосыф” әсәре. Р.Харис “Зөләйха”<br>Без-татар балалары. Г.Латыйп. “Минем нәсел”, Э.Шәрифуллина. “Без-татар балалары”.Нәсел агачы.<br>Ә.Рәшит “Нәсел агачы,Ф.Гыйрфанов. “Болгар ханнары шәҗәрәсе” картинасы,Х.Камалов. “Археолог”.<br>Су асты патшалыгында. Батулла “Су ияләре”.Су кызы. Н.Сәйяр. “Айсылу” , Айсылу – бәхетле бала.Ф. Яруллин “Буар елан” Р. Миңнуллин «Машина тавышлы көчек турында кечкенә әкият»<br>Г.Гыйльманов “Жавапсыз легенда”. Г.Вәлиева «Кызыктырсалар да». |
| Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша | Шигърият. Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы – шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм |

| | |
|---|---|
| табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез | халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм методикасы(тавышны күтәрү, түбәнәйтү)<br>Ш.Галиев “Жирдә мина ни кирәк?”, Ш.Галиев “Алсу дөнья”.<br>Шәехзадә Бабич шигырьләре. Ш.Бабич “Габдулла әфәнде Тукаев”, “Тын төн”.Р.Миннуллин “Утыз Имәнине укыганда туган уйлар”.Көзге табигать мизгелләре. К.Булатова “Кичә генә”, Р.Корбан “Ярдәм итик”, Г.Рәхим “Көзге урман”, М.Усманов “Урман күле”,О.Кульпин “Зәңгәр култык”, Г.Рәхим “Көз йөри”, М.Мирза “Көз”,”Кышкы сандугач.Г.Рәхим “Песнәк”. З.Ярмәки “Иртә”, Н.Думави “Беренче кар”. Р.Харис “Ак карлар арасында”.Әнкәм портреты.Г. Рәхим “Портрет, Ин матур сүз. Г.Сабитов “Чәчәк нигә боекты?”,Н.Исәнбәт “Өч матур сүз”. Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә. Л.Лерон “Кыхмырый, Мыхмырый һәм Шыхмырый”, И.Гыйләҗев “Тутыкмас тотка”.М.Әгъләмов «Матурлык минем белән». |
| Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз | Газаплы язмыш. Г.Галиев “Бибкәй аланы”.З.Бәшири “Бер асрауның аһ-зары».Кечкенә хезмәтче. Ф.Әмирхан “Кечкенә хезмәтче”.Н.Думави “Ятим бала”.Күз яшьле балачак. К.Нәҗми “Нәсимәнең беренче эш көне”,<br>.Маковскийның “Күрешү” картинасы.Д.Аппакова “Кечкенә Бануның тарихы”.Каникуллар -рәхәт вакыт. Г.Ибраһимов “Укудан кайткач”.Ф.Решетниковның “Каникулга кайтты” картинасы.Ф.Хөсни “ Малай белән солдат”.Р.Харис “Фронтовиклар”.Балачак хатирәләре. С.Хәким “Яратам мин”.Матурлык дөньяны коткара. М. Мәһдиев “Бәхилләшү” (өзек), Зөлфәт “Кыз тавы”. |
| Матурлыкның безгә ничек тәэсир итүен аңларга тырышабыз | Көннәрем гөрләп торсын. В.Хәйруллина “Хәерле көн”, Р.Миңнуллин “Иртән иртүк”.Д.Гайнетдинова “Исәнме, яна көн". Н. Әхмәдиев “Хәерле иртә!”Каен-урман чибәре. С.Гафарова “Көз”.И.Шишкинның “Каенлык”, К.Максимовның “Каенлык” картиналары. Ш.Галиев “Урман ява”.Р.Вәлиева “Бөтен дөнья ак кына”.Р.Гыйззәтуллин “Язгы моң”.М.Хәйретдиновның “Ана булу”,“Назлылык” картиналары.Серле күк.<br>Р.Мингалим “Бүген төнлә күккә кара”.Матурлык дөньясы. Л.Исхакова.”Шомырт чәчәкләре ак кына”<br>Туган як –Идел көзгесендә. К. Булатова“Шушы яктан, шушы туфрактан без”.К.Максимовның “Идел көзгесендә” картинасы. Туган көнгә – салават күпере.Батулла. “Салават күпере кайда йоклый?”.Табигать – серле дөнья. Ж.Дәрзаман “Бөҗәкләр белән сөйләшү”.Батулла “Терек-терек кырмыска”.Аккошлар- сак кошлар. Г.Хәсәнов “Аккош”, Р.Фәйзуллин “Быелгы яз”. А.Тимергалина “Аккош”.Сандугач-табигать жырчысы. Р.Миңнуллин “Атказанган сандугач”.К.Сибгатуллин “Бөтен кеше бүген шундый әйбәт”.. |
| Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә? | Тылсымлы, кодрәтле үлән. Г.Хәсәнов “Абага”.Кирлемән мажаралары. Р.Хафизова “Кирлемән».<br>Л.Толстой “Слива төше”, Р.Хисмәтуллин “Аһ, бер китсәң кирегә”.Урман докторы.Ж.Тәржеманов “Шуктуган”, Ш.Галиев “Тукран сые”.Ж.Тәржеманов “Тукран малае Шуктуган”.Гөмбәләр серен белү кирәк.<br>Н.Сладков “Тыштан ялтырый, эчтән калтырый”.Е.Зуевның “Урман хәзинәләре”картинасы.К.Тимбикова “Бану әби сабагы”.Аш пешерү хикмәтләре.Р.Рахман “Кесәл”.Татар халык ашлары. Э.Шарифуллина “Тормыш яме”, В.Кочуновның “Бәйрәмчә натюрморт” картинасы.Балалар дөньясы.Д.Гайнетдинова “Батыр Хәбир”.<br>Л.Гыймадиева “Кара урман, карангы төн».Бүрек-нәни көчек. Г.Гыйманов “Минем исемем Бүрек”<br>Бүрек-ышанычлы сакчы.В.Нуриев “Ачуланма инде, Илһам!” |

| | |
|---|---|
| Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз | Язучы катнашында үткән “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы.<br>Р.Вәлиев “Кошлар кайта”, “Кайтчы, Сөембикә”.Бәбкә үстерү хикмәтләре.Р.Вәлиев “Эт кояшы”, К.Насыйри. “Каз итен, коймакка төреп, каймакка манып ашау”.Чыпчыкнын да үз жыры бар. Мөҗәһит “Кемнең сайрыйсы килми?”, К.Сибгатуллин“Чыпчык”И.Туктар“Букет”, “Бер каен үсә”, Р.Корбан“Курай”.Яз галәмәтләре.<br>Р.Әхмәтҗанов “Безнең шигырь”, И.Гыйләҗев “Охшашлык”.А.Алиш “Сертотмас үрдәк”(әкият-пьеса).<br>В.Аршиновның “Яз билгеләре” картинасы. |
| Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк. Туган ил турында уйланабыз | Һәркемгә үз Ватаны кадерле.Р.Вәлиев “Ватаным”.Билгесез рәссамның “Сөембикә ханбикә үз гаиләсе белән” картинасы.Татарстан флагы. Р.Харис “Татарстан әләме”.В.Худяковның “Сөембикә ханбикәне Казаннан алып китү” картинасы.Балачакнын онытылмаслык истәлекләре.М.Мирза “Балачак хатирәсе”, С.Хәким “Тегермән стенасындагы язулар”.Авыр елларда. Р.Фәйзуллин “Минем эти”, Н.Каштан “Әрем исе”.<br>А.Ширяеваның “Авыр елларда” картинасы.Сөю-иң куәтле дәва. Р.Вәлиева “Онытма”, М.Җәлил “Дару”.<br>Кыю очучылар. Г.Кутуй”Яшен”, Ш.Рәкыйпов “Төнге очыш”.А.Пластовның “Фашист самолеты очып үтте” картинасы.Һәркемгә якын ул туган як. Г.Мөхәммәтшин “Туган як”, М.Галиев “Туган як”, Н.Исәнбәт “Туган ил”, Р.Харис “Туган җирем”. |

# 3. Тематик планлаштыру

## 1 сыйныф

| **Бүлекнең исеме** | **Сәг. саны** |
|---|---|
| Әлифбагача чор | 4 |
| Әлифба чоры | 39 |
| Халык авыз иҗаты һәм әдәбият | 4 |
| Әсәрнең эмоциональ тоны | 8 |
| Әдәби сәнгатьлелек чаралары | 6 |
| Әдәби жанрлар | 5 |
| **Барлыгы** | **66** |

## 2 сыйныф

| **Бүлекнең исеме** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|
| Белдекле Керпедә кунакта | 21 |
| Белмәмештә кунакта | 4 |
| Укымышлы Ябалак янында | 4 |
| Аю өенендә | 4 |
| Хыялда тудырган дөнья | 21 |
| Балалар газета-журналлары | 4 |
| Табигать-серле һәм җанлы дөнья | 4 |
| Көлек ничек туа? | 6 |
| Барысы | 68 сәг |

## 3 сыйныф

| **Бүлекнең исеме** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|
| Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз | 14 |
| Чагыштырулар серенә төшенәбез | 6 |
| Кешеләрнең хыялларын аңларга тырышабыз | 7 |
| Ярату турында | 8 |
| Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз | 8 |
| Көлке серләрен эзлибез | 5 |
| Герой ничек туа? | **9** |
| Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз | 11 |
| Барысы | 68 сәг. |

## 4 сыйныф

| **Бүлекнең исеме** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|
| Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез | 13 |
| Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз, ә автор әкиятләре хисләр дөньясына чакыра | 7 |
| Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез | 8 |
| Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз | 6 |
| Матурлыкның безгә ничек тәэсир итүен аңларга тырышабыз | 11 |
| Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә? | 10 |
| Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз | 4 |
| Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк. Туган ил турында уйланабыз | 9 |
| Барысы | **68** |